# Ел фасыллары.











## АЛТЫН КӨЗ

Сары төс — көз төсе. Сары төс — сагыш төсе, диләр. Сагышлы шул ул көз.

Кояшлы көннәрдә бакча, парк, урманнар алтынга манчылгандай була. Юкка гына көзне алтын димиләр. Алтын көзгә багышлап күпме шигырьләр, җырлар, картиналар иҗат ителгән! (Син кайсыларын беләсең?) Син дә бу матурлыкны альбом битенә төшереп кара әле. Буяуларыңны әзерлә. Сары буяу гына җитәрме? Юк шул, сары төс тә, кызыл төс тә кирәк. Әле зәңгәр дә, яшел дә кирәк икән. Башыңны күтәр: ачык күк йөзендә һәр яфракның үз төсе, кара, соры, шәмәхә «сипкелләренә» кадәр ялт итеп күренеп тора! Бар икән чуарлык, бар икән хозурлык! Табигатьнең шушы шатлыклы мизгелен күреп, тоеп калырга тырыш.

Бу — көз башы. Көннәр кыскара. Сизелерлек салкынайта. Күк йөзен авыр болытлар каплап ала. Менә иртәдән яңгыр сибәләргә тотына. Кайбер көнне иренеп кенә сибәләгән яңгыр кичкә кадәр туктамый. Салкын җил исә, көн караңгылана. Ә иртән ялт итеп кояш чыга. Күк йөзе шундый зәңгәр, шундый саф! Җир өстенә, ак җәймәдәй булып ап-ак томан сузылып яткан. Салкын. Җәйге төсен җуйган үләннәрдә энәдәй нечкә боз кисәкләре күренә. Кырау төшкән. Ак томаннар арасыннан, кызыл түгәрәк булып, кояш күтәрелә. Ул үзенең тансык нурлары белән җирне җылытырга тырыша. Акрын гына томан тарала.

Үләннәрдә чык тамчылары җемелди. Агач яфраклары тагы да саргайган, миләш, баланнар тагы да кызарган төсле. Әйтерсең бар да бәйрәмчә бизәнгән. Елгадагы су чиста, салкын зәңгәр төскә кергән. Һава бик саф һәм салкын. Тын, бәллүр кебек үтә күренмәле бу көннәрне «әбиләр чуагы» диләр. Борынгы заманнардан  ук әбиләр чуагы көзнең иң матур, иң әйбәт вакыты санала. Җәйге җылы кире кайткандай була.

Кояш җир өстен элеккечә үк җылытырга тырышса да, барыбер көз көзлеген итә. Һава көннән-көн салкыная бара. Гадәттә, 23 сентябрьгә җылы көннәр үтеп бетә. Көн белән төн озынлыгы тигезләшкән бу көнне «көзге көн-төн тигезлеге көне» диләр. Көннәр бик тиз кыскара бара. Октябрь аенда гына да көн озынлыгы 2 сәгать 20 минутка кими.

Яфракларның төсләре шундый матур, ачык, якты вакыты. Бар дөньяны алтынга манып, ялтырап кояш чыга, ул да булмый, салкын яңгыр ява башлый. Усал, ачы көзге җил, яфракларны ботакларынннан өзеп алып, әллә кайларга очыртып алып китә. Сары, кызыл, көрән, шәмәхә яфраклар, һавада бераз тирбәлеп очканнан соң, җай гына җиргә яталар. Агачлар ялангач кала. Алтын көз үтеп тә китә...





# Сентябрь

Үзе белән алтын көз ияртеп, сентябрь килде. Бакча-парклар, урманнар, әрәмәлекләр дә сары, кызыл, алсу һәм башка төсләргә кереп, чуарланып калдылар.

Алтын көз!.. Болай әйткәндә без табигатьтәге тышкы буяу-бизәкләрне генә күздә тотмыйбыз, әлбәттә. Көзнең алтынлыгы, аның кадере, барыннан да бигрәк, көзге муллык белән билгеләнә.

Көзге байлыкның шактый өлешен әле басулардан, җиләк-җимеш, яшелчә бакчаларыннан җыеп алырга кирәк. Бу яктан караганда, сентябрь дә, август кебек үк, авыл хуҗалыгында бик җаваплы ай булып санала. Элекке җирле календарьда хәтта аның исеме дә «ашлык сугу ае» дип аталган. Гадәттә, сентябрь уртасына көзге чәчүне һәм башка күп кенә кыр эшләрен тәмамларга тырышканнар. Бәрәңге һәм кайбер яшелчәләрне җыеп алу гына бераз соңгарак калдырылган.

Сентябрь дәвамында табигать эзлекле төстә көзгә күчә. Кояшның җылысы инде кузгә күренеп кими бара. Ай ахырында җил-яңгырлар ешая.





# Октябрь

Көз фасылының икенче ае — октябрь башланды. Халык телендә елның бу мизгелен кара көз дип тә йөртәләр. чөнки табигать инде үзендәге яшеллекне тәмам җуйды диярлек. Кырларда игеннәр урылды. Туңга сөрелгән басу өсләре дә күптән каралып калдылар. Урамнарны, юлларны көзге пычрак каплады.

Җитмәсә, әле октябрь — яктылыкка да шактый ярлы ай. Дөрес, елдагы иң кыска көннәр декабрьга туры килә, ләкин ул вакытта аяз көннәр күбрәк була, көн яктысына кар яктысы да өстәлә. Октябрьдә исә һәрвакыт диярлек болытлы, томанлы; көннәр аеруча сүрән, караңгы. «Көзен таң атып өлгерми, кич була»,— дип юкка гына әйтмәгәннәр шул.

Ачы җилләр исә. Һава температурасы һаман төшә бара. Аерым елларда октябрь суыклары хәтта $-20°C$ ка да җитә.

Беренче кар һәрвакыт күңелгә сафлык, сөенеч хисе алып килә. Әмма октябрь кары, гадәттә, озак ятмый.



# Ноябрь



Календарь буенча ноябрь көзнең соңгы ае булып исәпләнә. Ә безнең якларда ул еш кына кыш башы. Салкын көннән-көн көчәя, кар бөртекләре оча. Алар, ак күбәләкләр сыман, өй түбәләренә, агач ботакларына төшеп утыралар. Утыралар да юкка чыгалар.

Бу ай өчен һава шартларының шактый ук тотрыксыз булуы, җил-яңгыр, юеш кар, томанлы-буранлы көннәр хас. Халыкта «ноябрьдә бер болыттан кар да явар, яңгыр да явар» дигән сүз бар. Һаваның температурасы түбәнәя бара. Күзгә пычрактан тигезле-тигезсез булып калган җир өсте салкыннарда шыкырдап ката. Елга-күл өсләренә дә суык «балтасыз-тактасыз күпер» салып куя. Безнең якларда елга-күлләрнең боз белән каплануы 14—22 ноябрьләргә туры килә. Шушы ук вакытта диярлек, кар да ныклап ята.

Ноябрь башындагы тотрыксыз һава торышына карап тормыйча, кырларда, урманнарда, болыннарда булып калырга ашыгыгыз. Җир әле кар белән капланмаган; тун да, киез итекләр дә киеп торасы юк, авыр чаңгылар өстерәү дә кирәкми.





# КЫШКЫ ТӨСЛӘР

Әкрен генә кыш килә. Елга-күлләрне туңдырып, басу-кырларны карга күмеп, әкияттәге кебек, бер төн эчендә ул көмеш сарай сала. Бер көн иртән уянып китәсең дә, тәрәзәгә карап, хәйран каласың. Бөтен тирә-як ап-ак. Ул аклыктан ниндидер яктылык бөркелгән кебек. Сулыклар көзгедәй ялтыраган боз белән капланган. Үсемлекләр тирән йокыга талган. Салкыннар, бураннар вакыты, кыска көннәр, озын төннәр вакыты җиткән.

Бер караганда, кышкы төсләр бик гади кебек: кар — ак, күк — зәңгәр, агачлар — кара. Кышның башын, уртасын, ахырын бүлеп күрсәтү дә кыен төсле. Шулай да игътибар белән күзәтик әле.

Төрле елда кыш төрлечә килә. Бик иртә килсә, ноябрь башларында ук килеп җитә. Соңга калса, декабрьның икенче яртысында гына кыш башланды диярга мөмкин.

Кыш башында кояш бик аз җылыта. Аның төсе кура җиләге кебек кып-кызыл. Көн уртасында да ул горизонттан югары күтәрелми. Үзе гел болытлар артына яшеренә.

Ә болытлар, авыр булып, түбәннән агылалар. Күк йөзе тоныкь сүрән. Әле генә кар явып үтә, шул арада көчле салкыннар җепшек көннәр белән чиратлаша. Көн җылынып китсә дә, кызыгы юк: аяк асты юеш, пычрак. Җир өсте аклы-каралы. Кинәт туңдырып җибәрә. Көннән-көн салкынайта. Бар дөньяны сафландырып, ап-ак йомшак кар ява.

Иң кыска көн — 22 декабрь килеп җитә. Бу — кышкы кояш торгынлыгы көне. Моннан соң көннән-көн иртәрәк яктырачак, караңгылык соңрак төшәчәк. Кышның төп өлеше башлана гына әле. Кояш торган саен горизонттан югарырак күтәрелә, күбрәк яктырта. Коры салкын көннәрдә ул матур бөҗралар белән бизәлә. Алар һавадагы боз кристалларының кояш нурларында чагылуыннан барлыкка килә. Күк йөзе якты, аксыл-күгелҗем төстә. Көмеш төсле ялтыраган кар юрганы күзләрне чагылдыра. Сары, яшел, зәңгәр, кызыл очкыннар булып, кар кояшта ялтырый. Агачлар бәскә төренгән, әйтерсең, төрле төсләргә кереп җемелдәүче киемнәрен киеп, бәйрәмгә әзерләнгәннәр. Җепшек көннәрдә кар инде эреми, бары тик юешләнә, авырая, сылана гына. Кар атышып уйнарга, кар шәһәрләре төзергә, кардан сыннар ясарга менә дигән материал! Кыш сиңа скульптор, архитектор һәм художник рольләрендә булырга да мөмкинлек бирә.

Кояшлы аяз көннәр салкын җилләр, карлы бураннар белән чиратлаша. Кышның бу төп өлеше февраль башына, зур песнәк сайравына кадәр дәвам итә.

Ә менә песнәк сайрап җибәрсә, белеп тор: кышның соңгы чоры башлана. Бу чорны сурәтләү өчен күбрәк зәңгәр төс чаткылары кирәк. Агачлардан төшкән күләгәләр дә зәңгәр, кар көртләре дә күкселләнеп киткән. Күк йөзе дә көннән-көн зәңгәрләнә бара, болытлар да инде соры түгел, аксыл өемнәр булып йөзәләр. Кояш тагын да югарырак күтәрелә, аның җылытуыннан агач төпләрендә кечкенә чокырлар хасил була. Көннең озайганы яхшы сизелә. Кояшлы көннәрдә түбәдә яткан карлар эри башлый, тамчы тама. Салкын һавада бу тамчылардан ялтырап торган матур боз сөңгеләре барлыкка килә. Көндез кояшта йомшарып киткән кар өсте төнге салкында боз булып ката.

Ләкин кыш әле бирешми. Зәһәр суыклар да, көчле бураннар да буласы бар әле. Кышның соңгы чоры март урталарына кадәр дәвам итә.

# Декабрь

Елның иң соңгы — уникенче ае ул декабрь. «Декабрь елны тәмамлый, кышны башлый» диләр халыкта. Чыннан да кыш декабрьдән башланамы? Метеорологлар, кыш безгә ноябрь аенда ук килә, диләр. Ә фенологлар, барлык елга-күлләр туңып беткәч кенә кыш килеп җитә, дип саныйлар. Астрономнар исә, кыш 22 декабрьдән башлана, диләр. Кояшның төш вакытындагы биеклеге берничә көн үзгәрешсез калганлыктан, 22 декабрьне «кояш торгынлыгы көне» дип атаганнар. Кышкы кояш торгынлыгын борынгы халыклар ел саен бик зурлап, тантаналы төстә билгеләп узганнар. Мондый бәйрәм татарларда «Нардуган» дип йөртелгән. Елның иң кыска көннәре шушы вакытка туры килә. Декабрьдә көн озынлыгы 7 сәгатькә кадәр кыскара. 22 декабрьдә кояш — җәйгә, кыш суыкка борыла, диләр. Дөрестән дә, алда әле чатнама суыклар, котырган бураннар буласы бар. Ләкин кыска көннәрнең вакыты бетә. 23 декабрьдән башлап көннәр озая башлый. Бу айда кыш җиребезгә тәмам урнашып җитә. Төньяктан исүче салкын җилләр һаваны көннән-көн суыта. Кайчакта һаваның температурасы 30° С тан да түбән төшә. Андый суыкларны «төкерек җиргә төшмәслек» яисә «гармунсыз биетә торган» диләр.

Сулыкларны каплап алган боз калыная, ныгый бара. Балалар рәхәтләнеп тимераякта шуалар. Олылар да, юлларын кыскартып, бер шикләнмичә, боз өстеннән йөриләр. Ә Идел, Кама, Вятка кебек зур елгаларда боз өстеннән кешеләр генә түгел, хәтта машиналар да йөри. Кышкы боз ышанычлы. Елга-күлләрдәге боз өстенә балыкчылар сибелә. Бораулары белән бозны тишеп, алар балык тота башлыйлар. Декабрьдә чуртан, алабуга, кушбашлар, шамбы шәп эләгә. Балыклар һава торышына бик сизгер. Көчле суыкларда һәм салкын җилләр искәндә балык чиртми, диярлек.

Декабрь аенда безнең урманнарда куян, төлке, кабан дуңгызы, поши аулау дәвам итә. Ау сезоны ноябрь аенда ук ачыла. Урман һәм аучылык хуҗалыклары, кайсы җәнлекне күпме ауларга мөмкинлеген исәпләп, аучыларга *лицензия* (рөхсәт кәгазе) бирәләр. Тәҗрибәле аучылар кардагы җәнлек эзләрен ак кәгазьдән укыгандай, бик җиңел таныйлар.

Декабрь — күп кенә кошлар һәм җәнлекләр өчен шактый авыр вакыт. Чөнки бөтен җан ияләрен туендырып торучы җир кар астында калган. Урман хуҗалыгы хезмәткәрләре бу вакытта пошилар һәм куяннар өчен усак агачлары кисеп аударалар. Көртлекләр һәм урман тавыкларын орлыклар белән, кабаннарны имән чикләвеге, бәрәңге һәм чөгендер белән, кыр кәҗәләрен печән һәм яфрак себеркеләр (миллекләр) белән сыйлыйлар. Менә дигән урман ашханәсе!

Җәйге һәм көзге чор белән чагыштырсаң, авылларда кыш көне эш калмаган сыман. Ләкин бу һич тә алай түгел. Барлык мал-туар абзарда. Аларны ашатасы да, эчертәсе дә, асларын җыештырасы да бар. Кайбер терлекләр кыш көне балалый. Яңа туган бозауларны, бәрәннәрне салкыннан да, авырулардан да сакларга, аеруча тырышып тәрбияләргә кирәк. Басуларда да эш җитәрлек. Басуларда кар тота башларга вакыт, кырга тирес чыгарырга, киләсе ел уңышын кайгыртырга кирәк.





## Гыйнвар

Һәр яңа ел гыйнвардан башлана. Гыйнвар — кышның икенче ае, кыш уртасы. Инде көчле салкыннар да, котырган бураннар да шаккатырмый. Табигать, кар юрганына төренеп, тынычланып калган сыман. Тукай әйтмешли «Җир йоклый тыныч, күреп тәмле төш».

Салкыннан аяк астында кар шыгырдый; чәчләргә, керфекләргә бәс куна, авыздан пар чыкканы күренә. Аяз көндә күк йөзе зәңгәр, кичен анда якты йолдызлар яна. Салкын. Төньяктан салкын һава килгәндә, температура минус 40—45 градуска кадәр төшәргә мөмкин.

Көннәр озынрак һәм яктырак була бара. Башта бу сизелми дә. Ай ахырына таба гына көн озынлыгы сәгать ярымга арта. Кояш көннән-көн югарырак күтәрелә һәм күктә озаграк тора. Ә күк йөзе зәңгәрләнә бара.

Урман әче бөтенләй тынып калган чак. Агач ботакларындагы кар мендәрләренә кагылсаң, ак тузанга чумасың. Тирә-як әкияттәгедәй матур. Асылташлар кебек төрле төсләргә кереп, кар ялтырый. Кар өстендә — җәнлек эзләре. Ләкин үзләрен күрермен димә. Кайсысы кышкы йокыга талган, кайсысы кышкы киемнән булганга күренми — урман бөтенләй тынып калган кебек. Ләкин игътибар белән күзәтсәң, тукран, үрмәләч кебек кошларны очратырга була. Алар, агач кайрылары астына яшеренгән бөҗәкләрне, аларның личинкаларын эзләп ашыйлар, шуның белән урманнарга зур файда китерәләр. Урман тавыклары, көртлекләр, суерлар да үзләренә азык табалар. Кайчакта урманда аларны да очратырга була.

Игенчеләр гыйнварда алдагы ел уңышын кайгырта башлыйлар; язгы һәм җәйге эшләр өчен техника ремонтлау башлана. Фермалардан басуларга тирес чыгаралар, терлекчеләр йорт хайваннарын тәрбияли.



# Февраль

Февраль — кышның соңгы ае. Башка айлардан аермалы буларак, февральдә көннәр саны кимрәк. Гыйнварның көне кыска, февральнең ае кыска, ди халык.

Һава торышы ягыннан ул гыйнвардан әллә ни аерылмый. Күз ачкысыз бураннар, битләрне чеметтереп ала торган суыклар — бу айда гадәти күренеш. Кайбер көннәрдә һава температурасы –35 градуска кадәр төшә. Кар катламы арта бара. Кайбер көннәрдә томан төшә, юлларда бозлавык була. Февральдә кар көртләренең иң биек, иң зур вакыты. Көндезләрен кояш бераз җылыта башлый. Кар өсте эреп, йомшарып китә. Төннәрен салкынайта, кар өсте бозланып ката. Өй түбәләреннән боз сөңгеләре сузыла.

Февраль — каршылыклар ае. Бу айда кыш яз белән көрәшә. Февраль кояшы көннән-көн югарырак күтәрелә. Ул инде күбрәк яктырта: ай буена көн озынлыгы 2 сәгатькә арта. Халыкча әйтсәк, «декабрьдә көн — чыпчык адымы, гыйнварда — карга адымы, февральдә ат адымы кадәр озыная».

15 февральдә кыш белән яз очраша, дип санаганнар. Шушы көндәге һава торышына карап, язның нинди булачагын чамалаганнар. Җепшек булса, яз иртә килер һәм җылы булыр, кар яуса, яз озак һәм яңгырлы булыр, салкын булса — яз да салкын булыр, дигәннәр.

Кошларның үз-үзләрен тотышлары үзгәрә. Тукраннар, барабан каккандай, агач шыкылдаталар, тын урманда үрмәләч сызгыруы, чыелдыкның көмештәй җыры ишетелә. Күктә козгыннар, бер-берсе белән куышып, уйнаклап оча башлыйлар. Хәтта ала карга һәм чәүкәләрнең дә очышлары, тавышлары үзгәрә. Песнәкләрнең язгы җырлары көннән-көн ачыграк, матуррак яңгырый. Бу — күп кенә җәнлекләрнең парлашу вакыты.



# ЯЗЛАР НИЧӘҮ БУЛА?

Язга хас төп төсләр — ачык зәңгәр һәм яшел, мөгаен. Урамнарда аккан зәңгәр гөрләвекләр, анда-монда кар астыннан чыккан чирәмнәр яшеллеге, агачларда яшел ут булып балкучы яңа гына ярган яшь яфраклар — болар яз билгеләре. Кошларның гадәттән тыш матур кауырыйларын, төсле бакаларны, назлы чәчәкләрне бары тик яз көне генә күреп була. Башка ел фасылларыннан аермалы буларак, язгы төсләр ялтырыйлар. Йортлар да ялтырый, язгы кар да, гөрләвекләр һәм җыелып торган сулар да ялтырый, яшел яфраклар һәм үләннәр, беренче чәчәкләр һәм кош кауырыйлары шулай күз камаштыргыч булып бары яз көне генә ялтырыйлар.

Бер сезон эчендә без дүрт язны каршылыйбыз дип, берәүнең дә башына килми торгандыр. Ә бит алар һәрберсе үзенең характеры, үз үзенчәлекләре һәм үз исеме белән: *Яктылык язы, Су язы, Яшеллек язы* һәм *Җәй алды*.

Яз башы — **Яктылык язы.** Без аны март аенда ук күзәтәбез. Бер карашка, урамнарда бернәрсә дә үзгәрмәгән кебек: шул ук кар, шул ук агачлар. Бары тик кояш кына күз камаштыргыч якты, аның нурлары астында эри башлаган карның бәллүр сыман ялтыравык аклыгы күзләрне авырттыра. Кар өстендә ачык күренеп торган күләгәләр бу вакытта аеруча матур: алар күк йөзеннән зәңгәр төскә, батып баручы кояштан аксыл шәмәхә төскә, җирдән — коңгырт-сары төскә керәләр.

Иртә язда һава үтә күренмәле, саф һәм салкын. Кояшлы көннәрдә күк йөзе зәп-зәңгәр. Анда тыгыз ак болытлар агыла. Әйтерсең күк йөзендә бозлар ага. Ул болытлар чыннан да боз кристаллчыкларыннан тора, шулай булгач, күктә бозлар агымы башланган дию дә дөрес. Тәүлекнең якты өлеше һаман арта бара, һәм, ниһаять, бөтен җирдә төн озынлыгы белән көн озынлыгы тигезләшә. Шуңа күрә 21 март язгы көн-төн тигезлеге көне дип йөртелә. Хәзер көн озынлыгы һаман арта барачак. Чын яктылык бәйрәме!

Яктылык һәм җылылык беренче бөҗәкләрне уята, кошлар кайта башлый. Агач һәм куакларда беренче чәчәкалкалар ачыла. Аларга карап, табигать календарендә вакыйгалар чиратлашу срокларын билгеләргә була. Чикләвек һәм зирек чәчәк аткач, язның яктылык чоры үтә.

Урыны белән, аерым тап булып кына, ә кайдадыр буй-буй булып, кар астыннан җир күренә башлый. Кар эри, кыш буена җыелган кар һәм боз өемнәре, язгы җылыдан эреп, суга әйләнә. **Су язы** башлана. Аның башы үги ана үләненең чәчәк ату вакыты белән туры килә. Кар тоткынлыгыннан котылган язгы сулар урамнарны тутыра, җирне туендыра. Юллардагы гөрләвекләр, төрле төсләргә кереп, кояшта ялтырыйлар. Елгалар ярларыннан чыга — ташу башлана. Төннәрен еш кына суыта. Агачларда һәм суынган өслекләрдә дым иртән бәскә әйләнә. Җылы һава килеп, көчле парга әйләнүдән, томан төшә. Соры, җылы, юеш томан карны кояштан да болай ашый. Төньяк җилләре апрельдә тагын салкыннар алып килә. Суык белән җылы аяусыз көрәшәләр. Караңгы болытлар күк йөзен каплап ала, үзәккә үтә торган салкын җилләр исә, җепшек кар ява башлый. Ләкин озакка түгел. Ялтырап кояш чыга, кар эри, тагын җылыта. Үләннәр яшәрә, төклетуралар оча, бакалар сикерешә башлый. Җир йөзен бөтен чүпләрдән, пычраклардан арындырырга теләгәндәй, сулар ага.

Май башында, каен яшәрү белән, **Яшеллек язы** башлана. Көннәр эссерәк, төннәр җылырак була бара. Агачлар яфрак яра. Тирә-якта яшеллекнең нинди төсмерләре генә юк! Тәүлек буе бертуктамый кошлар сайрый. Шомырт чәчәк ата, әйтерсең бәйрәм итәргә хәбәр булган. Җиләк-җимеш бакчаларындагы агачлар ак, ал чәчәкләргә күмелә. Дөнья хуш ис белән, күңелләр шатлыклы хисләр белән тула. Яшел газоннар сары чәчәк атучы тузганаклар белән каплана. Паркларда, урманнарда хуш ис бөркеп, ландышлар чәчәк ата. Күк күкри, яшен яшьни. Тирә-якны тагын да сафландырып, эре тамчылы яңгыр явып үтә.

Язның беренче яңгырын *ләйсән* дип атауларын сез инде беләсездер.

Сирень чәчәк ату белән, язның соңгы чоры — **Җәй алды** башлана. Агачлардагы ак чәчәкләр коела. Яшеллек төсмере үзгәрә. Агачлардан иң соңгысы булып, имән яфрак яра. Күчмә кошлар кайтып бетәләр. Бакалар бакылдавы һәм кошлар җыры тынып кала. Табигатьтә төсләр көн дә алмашына. Күктә берсеннән-берсе гаҗәп формалы болытлар йөзә. Бакчаларда, паркларда, клумбаларда көн саен яңа чәчәкләр күренә. Кыргый роза — гөлҗимеш чәчәк ата, димәк, яз китә.







# Март

Март — язны башлаучы ай. Жиргә яз килә. Ләкин кыш әле чигенергә теләми, яз белән тартыша. Кайчакта төнге салкыннар февральдәгедән уздырып җибәрә.

Зәңгәр күк ачылып, кояш караса, өй түбәләреннән тамчы тама башлый. Бозлы кар өстендә биешкән тамчылардан кечкенә күлдәвекләр җыела.

Кошлар бар да кышны исән чыга алуларына куанган сыман. Каты салкыннар, ачы бураннар кичергән песнәкләр язны җыр белән каршылый. Чыпчыклар бөтен ишегалдын шаулаталар, шатланып чыр-чу киләләр. Парлашып, тәрәзә башына кунган күгәрченнәр гөлдер-гөлдер серләшәләр.

Ерактан, зәңгәрләнеп, урман күренә. Ул да язга әзерләнә. Агач кәүсәләреннән кар өстенә зәңгәр күләгәләр сузылган. Каеннарның матурлыгына сокланып туймаслык. Өскә карасаң, зәп-зәңгәр күк гөмбәзе күзләрне иркәли.


Урман аланында көртлекләр язгы туйларын башлыйлар. Ата көртлекләр, күркәдәй кабарынып, көч сынашалар. Канат очлары кар өстендә пар-пар эзләр калдыра. Ана көртлекләр, агач ботагына утырып, әтәчләр көрәшен күзәтәләр.

Тиеннәрнең балалары туа. Ата-аналарының мәшәкатьләре арта. Чәшке, сусар, көзән һәм башка җәнлекләрнең туннарын алыштыру вакыты җитә. Бар тереклек язга әзерләнә, яңа буын үстерү турында кайгырта.

Төннәр һаман кыскара, көннәр озая. 2 мартта, ниһаять, көн белән төн тигезләшә. Кояш календаре буенча бу көн яңа елның беренче көне булып исәпләнгән. Бу көнне, өйдән-өйгә йөреп, нәүрүз әйтү һәм бүләк җыю киң таралган булган. Нәүрүзчеләр йорт хуҗаларына яңа елда сәламәтлек, тынычлык, кырларга бай уңыш, мал-туарга үрчем теләгәннәр.

Яз сулышын агачлар һәм куаклар да тоя. Өрәңге, каен, зирек агачларына җан керә — кәүсәләрендә су йөри башлый. Таллар чәчәк ата — «песи» чыгара башлый. Шау-гөр килеп, җылы яклардан кара каргалар кайта. Аларның кайтуы язга ямь өсти. Кайтып җитү белән, алар оя кора башлыйлар. Карга кайтып шунда ук ояга утырса, яз бердәм, тиз килер, диләр. Димәк, кырга чәчүгә чыгарга санаулы көннәр кала. Игенчеләр ашыга. Язгы көн ел туйдыра, диләр.

Бакчачылар да язны түземсезлек белән көтеп ала. Мартта алмагач кәүсәләрен акшарлыйсы, куерган ботакларны кисәсе бар. Ботаклар кисүне бөреләр бүртә башлаганчы тәмамларга кирәк. Яшелчә үстерү турында да кайгыртырга вакыт. Көздән әзерләп куелган туфракны тартмаларга салып, аларга орлыкларны утырталар. Мартның башында баклажан, борыч, помидор орлыклары, ә азагында кәбестә орлыгы чәчәләр. Яшь үсентеләрне карап торырга, вакытында су сибәргә, сирәкләргә кирәк.





# Апрель

Апрель җитсә, яз җитәр, эреп-агып кар китәр, ди халык. Апрель — язның икенче ае. Кояш җиребезгә җылысын да, яктысын да бик юмарт бирә. Кар күзгә күренеп эри. Яңгыравык тавышлы гөрләвекләр елгаларга таба юл ала. Су язы башлана. Инеш-елгалар боз капламыннан арынырга талпына. Язгы боз ястык калынлыгы булса да ышанма, дигәннәр. Беренче карашка калын тоелса да, боз өстенә керергә һич ярамый. Чөнки көпшәкләнгән, йомшарган боз ярылырга гына тора. Ярылган, ватылган бозлар елга буйлап түбәнгә ага башлыйлар. Боз китүләр, су ташулар — табигатьнең гаҗәеп матур күренеше. Боз киткәнне карарга төшсәгез, су белән ашалган ярның кинәт ишелеп төшүе мөмкин икәнен онытмагыз.

Барлык болыннарны, тугайларны тутырып су арта. Март аенда әле тау башлары гына кардан арчылган булса, апрельдә инде бар җирдә кар эреп бетә диярлек. Кырлар тәмам карала.

Көн узган саен, табигать уяна, җанлана бара. Җылылык һәм дым үсемлекләргә яшә сулышын өрә. Һава ук икенче. Ул кар сулары, язгы җир исләре белән тула. Агачларның бөреләре ярылырдай булып бүртә. Иң элек зирекләр чәчәк ата. Алар, купшыланып, озынча кызгылт алкалар тага. Чикләвек куаклары да сары алкалар аса. Тал песиләре алтынга манчыла, озынча сары серкәчләр өстендә бал кортлары, төклетуралар мәш килә. Алар беренче нектарны җыярга ашыгалар. Кырмыскалар, ояларыннан чыгып, агач кәүсәсенә үрмәлиләр, тәмле каен суы эчәләр. Кычыткан күбәләге дә йокысыннан уяна.

Апрель — кошлар ае. Аларның күпчелеге безгә шушы көннәрдә очып кайта. Кояш астындагы зәңгәр биеклектә тирбәлә-тирбәлә, көн буе тургайлар сайрый. Тургайлар артыннан туган якларына сыерчыклар кайтып җитә. Әзер матур ояларга куанып, җырлый-җырлый, үзләренә оя ясап куйган кешеләргә рәхмәт укый алар. Кыр казлары, торналар да туган күлләренә, сазлыкларына кайталар. Алар белән бергә акчарлаклар, кыр үрдәкләре кайта. Сулыклар шулар тавышына күмелә.

Апрельдә язның беренче чәчәкләре күренә. Яр буйларында үги ана яфрагы чәчәк ата. (Үги ана чәчәкләре күренгән көнне истә калдырыгыз: гадәттә, шуннан соң 32 көн үткәч, алмагач чәчәк ата башлый.) Урманда язның иң матур гөлләре — баллы-татлы күкебашлар, нәүрүз гөлләр, умырзаялар баш калкыта.

«Язгы ташулар куәтле булса, ашлык яхшы уңар», дияр. «Сабан чәчсәң — суга чәч» дигән мәкаль язгы чәчүне вакытында башларга кирәклеген кисәтә. Игенчеләр язгы чәчүгә төшә. Бакчачылар узган елгы ботак-яфракларны, чүпләрне җыештыралар, агач кәүсәләрен акшарлыйлар. Яңа агач һәм куак үсентеләрен дә апрельдә утырталар. Ай ахырына таба кишер, редиска, укроп, петрушка кебек салкынга чыдам яшелчәләрне чәчәләр. Язгы кыр эшләрен башлау, туфрак әзерләү, төрле культураларны чәчүнең сроклары язның ничек килүенә бәйле.





# *Май*

Май — язның соңгы ае. Карлар инде тәмам эреп бетә. Көннәр кояшлы, җылы, якты. Төннәрен дә һава артык суынмый. Май ае табигатьнең яшәрүе, чәчәк атуы өчен бөтен шартларны тудыра. Яшен яшьнәп, күк күкрәп, җылы яңгырлар явып уза. Кояшның шифалы нурлары астында үләннәр, уҗым һәм сабан ашлыклары бердәм күтәрелеп китәләр. Җир өстендәге яшел келәмгә төрле чәчәкләр сибелә. Урман-әрәмәлекләрдә, бакча-паркларда бер-бер артлы агачлар, куаклар яфрак яра башлый. Шомырт һәм сиреньнәр чәчәк атарга да өлгерә. Җылыга куанып, кешеләр җәйге җиңел киемгә күчәләр. Ул да булмый, көннәр кинәт суытып җибәрә. Бабайларның: «Майда туның калдырма»,—диюләре дөрес икән. Төннәрен кырау төшкәли. Алмагачлар, чияләр шау чәчәктә утырганда төньяктан салкын җил исә. Аерым елларда кар яву очраклары да була. Тик бу — кыска вакытлы күренеш.

Һавада кичләрен май коңгызлары гүелдәп оча. Димәк, иртәгә көн аяз булачак. Кырмыскалар, ояларына керү-чыгу юлларын ачык калдырып, өем өстендә ыгы-зыгы киләләр. Бу да көннең яхшы булачагы турында хәбәр.

Апрель азагында башланган «бакча айлыгы» дәвам итә. Парк һәм урамнарда агачлар утыртыла, чәчәк түтәлләре әзерләнә. Укучылар да өлкәннәрдән калышмый. Алар мәктәп бакчаларында карлыган, крыжовник, чия һәм алмагачлар утыртала. Яшелчә орлыкларын чәчүгә әзерлиләр.

Чәчү өстендә вакыт кадерле. Моны игенчеләр бигрәк яхшы аңлый. Май аенда уҗым тукландыру, туфрак әзерләү, сабан культураларын чәчү, бәрәңге, яшелчә утырту кебек эшләр берсе икенчесенә ялганып, өстәлеп кенә тора. Шуңа күрә татар халкында майны «сабан ае» дип йөртәләр.



# ҖӘЙГЕ БИЗӘКЛӘР

Кызу, кояшлы, озын-озын көннәре белән җәй дә килеп җитте. Табигать үзенең бөтен булган буяуларын аңа сипте. Җәй — үсемлекләр һәм бөҗәкләр чоры. Алар белән танышырга, тормышларын өйрәнергә иң җайлы вакыт. Ә менә кошларга, хайваннарга комачауларга кирәкми, чөнки аларның җитди мәшәкатьләре күп: балаларын ашатасылары бар, күз җиткәнче аларны күп нәрсәгә өйрәтергә, үстереп җиткерергә кирәк.

Башка һәрбер ел фасылындагы кебек, җәйнең дә башы, уртасы, азагы бар. Аларны аеру бик җиңел түгел. Ләкин күзәтүләр сиңа һәрчак ярдәм итәр.

Гөлҗимеш белән баланның чәчәк атуы җәй башлануы турында хәбәр итә. Гадәттә җәй башы салкынчарак була. Июньнең беренче ун көнендә һава торышы еш алмашына. Җылы, кояшлы көн кинәт бозыла: салкын җил исә, яңгыр ява башлый. Айның уртасыннан кызу көннәр башлана. Кояш нурлары астында аланнар, газоннар алтын-сары келәм булып балкыйлар: тузганаклар чәчәк ата. Агачлар куе яшел төскә күмелә. Шушы сары-яшел фонда көн саен яңадан-яңа чәчәкләр барлыкка килә.

22 июнь — җәйге кояш торгынлыгы көне, елның иң озын көне. Күк йөзендә зәңгәрдән яшелгә, аннан сары, кызгылт һәм горизонт өстендә үк куе кызыл төсләргә кереп балкыган кояш баешы сүнеп тә бетми, диярлек. Күктәге якты юл көнбатыштан көнчыгышка күчә дә берничә сәгатьтән тагын аллана, яктыра, таң ата. Төн бөтенләй юк диярлек. Алар берничә көн якты һәм кыска була. 25 июньнән соң һәр килер көн бик азга булса да кыскарак, ә төннәр караңгырак була бара.

Җәй уртасы юкәнең чәчәк атуыннан башлана. Ул гадәттә июль башына туры килә. Июль — елның иң җылы һәм дымлы ае. Иртә таңнан үләннәр өстенә чык төшә. Беренче кояш нурларында алар бәллүр тамчылардай җемелдәшәләр. Ә көндез, кызу кояш нурлары астында, җирдәге дым, парга әйләнеп, һавага күтәрелә.

Июль яшенле яңгырларга бай. Коеп яуган яңгырдан, күз ачып йомганчы, җирдә су ташкыннары барлыкка килә. Ләкин эсседән яңгыр суы бик тиз парга әйләнә һәм җир өсте тагын кибә.

Елгалар саега, сай сулыкларда суүсемнәр үрчи, һәм су ачык яшел төскә керә. Агачлардагы яшеллек куера. Җирдәге сары келәм агара, чалара, чуарлана.

Каендагы беренче сары яфрак җәй азагы җитүен хәбәр итә. Җәйнең соңгы ае — август башлана. Кояш шулай ук якты, кыздыруы гына бераз кимегән төсле, көннәр җылы тора. Күк йөзе биек, чиста, һава саф. Күкнең зәңгәрлеге һаман арта кебек. Коеп яуган яшенле яңгырлар тына. Еш кына кичке күк йөзен аҗаган балкышы яктырта (бик еракта ялтыраган яшен чаткыларын аҗаган диләр). Төннәр аяз, йолдызлы. Чәчәкләр арасында зәңгәр һәм шәмәхә төсләр күбәя. Агачлардагы яшеллек тагын да куера төшә. Бакчаларда һәм паркларда затлы декоратив үсемлекләр чәчәк ата.

Август урталарыннан башлап, эсселек кими. Салкын төньяк җилләре искәли. Төннәрен томан төшә. Беренче кояш нурларында ул ал болыт булып күтәрелә дә, һавада эреп, юкка чыга. Сулыкларда су суына, чистара, яшеллеген югалта. Аның көзге сыман өслегендә күк йөзе чагыла. Көннәр кыскара, төннәр караңгылана бара. Җәйнең соңгы көннәре. Август — җәй азагы. Алда — көз.



## Июнь

Бар дөньяны яшеллеккә, шау чәчәккә күмеп, ямьле җәй килә. Июнь — җәйнең беренче ае.

Авыл болыннарын, шәһәрнең сквер-паркларын тоташ сары төскә манган тузганак чәчәкләре тирә-юньгә җәй исе тарата. Урманда гөлҗимеш чәчәк ата. Җәй гөлҗимешнең беренче чәчәкләреннән башлáна, ди халык.

Июнь ае җылы яңгырлары, нурлы кояшы белән үзенчәлекле. Аллы-гөлле чәчәкләр, җиләк җимешләр, сайрар кошлар да хас аңа. Июнь аенда төннең озынлыгы бер саплам, диләр. 20—27 июньдә төннәрнең иң кыска, көннәрнең иң озын вакыты.

Кошлар җырыннан гөрләп торган урман июнь ахырларында тынып кала. Алар бала үстерү белән мәшгуль. Кыргый хайваннар кышка запас туплыйлар, организмнарына кирәкле матдәләрне җыеп калырга тырышалар.

Табигатьнең иң җанланган, бакча-кырларда эшнең иң кызган чагы. Апрель азагында, майда утыртылган үсемлекләрне карау, чүпләрен утап, төпләрен йомшарту, ашламалар сибү, үсентеләр күчереп утырту — барысы да күп игътибар сорый торган эшләр. Кырларда чәчү, сабан эшләре беткәч, бәйрәм уздыралар. Бу — татар халкының иң күркәм, иң күңелле, иң яраткан бәйрәмнәреннән берсе — **Сабантуй**. Авылның яше-карты, бала-чагасы уңганлыкта, осталыкта, җитезлектә көч сынаша, күңел ача.

Сабан туйлары узу белән, авыл халкы печәнгә төшә. Кышын мал-туар тук булсын өчен, җәй көне тырышырга кирәк. Болыннарда, урман буйларында чалгы чыңнары яңгырый. Бу — үсемлекләрнең иң нык үскән, җиләк-җимешнең тәм җыйган вакыты, дару үләннәрен хәзерләү чоры. Бал кортлары көннәр озын чакта кәрәзләрен бал белән тутырырга ашыгалар.

# Июль

Июль — җәй уртасы гына түгел, ел уртасы да. Көн озынлыгы акрынлык белән кими башлый. Көннең кыскаруы ай дәвамында сизелерлек тә түгел. Зәңгәр күктән кояш шундый кыздыра, һавада рәшә тирбәлә башлый. Июль аендагы бу кызу чорны «җәйге чиллә» диләр.

Июль — яшенле яңгырларның да бик еш була торган чоры. Игеннәр, җиләк-җимешләр, яшелчәләр өчен явымнарның шифа-файдасы чиксез зур. Барлык агач һәм үләннәрнең дә күкрәп үскән чагы бу. Бөтен яшеллектән аңкып торган хуш ис июль аена гына хас. Ай дәвамында йөзләгән төр үсемлек чәчәк ата. Аланнардагы куе, сусыл үләннәр дә, өй каршында утыручы ясмин куагы да хуш ис бөрки. Юкәләр шау чәчәккә күмелә. Умарта кортлары иң шифалы юкә балын күбрәк әзерләп калырга тырыша. Халыкта июльнең «балкуар ае» дип йөртелүе дә тикмәгә түгел.

Урман ачыклыкларында, болыннарда июнь ахырыннан бирле чалгы чыңы, машиналар гөрелтесе тынмый. Терлекләр өчен кышка печән әзерләү дәвам итә. Кырлар урыны-урыны белән алтынсу төскә манчыла. Арыш, арпа башакларында гәрәбәдәй бөртекләр өлгереп килә. Бодай баш чыгара. Басуларда борчак чабарга керешәләр. Урак өсте килеп җитә.

Июльнең яшенле җылы яңгырларыннан урманда гөмбәләр калка. Каен һәм усак гөмбәләренең исемнәре үк аларны кайдан эзләргә икәнен әйтеп тора. Ә ак гөмбәне наратлык һәм чыршылыкта очратырга була. Урманда абага яфракларына игътибар итегез. Аларның бөтерелеп өскә каравы бүген-иртәгә яңгыр явасын хәбәр итә. Черкиләрнең биткә сарылып йөдәтүе дә шуңа. Халык сынамышларының күбесе явым-төшем турында.

Күп кенә дару үләннәре: меңьяфрак, мәтрүшкә, бөтнек һ.б. чәчәк ата. Һәр үләнне җыюның үз вакыты бар. Халыкта ул, гадәттә, «Питрау көне» (12 июль) белән билгеләнә. «Питрауга чаклы үләннең шифасы чәчәктә, Питраудан соң тамырда» диелә бер сынамышта. Дару үләннәренең шифасы, алардан файдалану ысуллары турында халыкта әллә никадәр мәкальләр, киңәшләр бар.

Питраудан соң урманда кошлар сайравы ишетелми. Алар бу вакытта балаларын үстерү белән мәшгуль. Сандугачлар, тургайлар да шушы көн җиткәнче генә сайрый, диләр. Әгәр бу кагыйдәләрдән тайпылышлар булса, шуларга карап, кешеләр көзнең ничек киләчәген чамалап куялар.

Җәнлекләр дә бала үстерә. Ашарга азыкның мул һәм төрле чагы, аларны таба белергә генә кирәк. Өйрәтергә әниләре дә янда гына. Алар балаларын ерткычлардан качарга да, азык табарга да өйрәтәләр.



## Август

Август — җәйге кызу айларның берсе. Телебездәге «уттай урак өсте» дигән чагыштыруда эшнең кызулыгы гына түгел, көннең кызулыгы да күздә тотыла. Аны, июль ае кебек үк, чиллә ае дип атыйлар. Көндезләрен эсселек +35°C ка кадәр җитә. «Август җитте — эш җитте, урак җитте — җәй бетте» ди халык. Димәк август — җәй белән саубуллашу ае.

Җәй үз көчендә калса да, агачларда көз хәбәрчесе — сары яфраклар күренә башлый. Көз сулышы ныграк сизелгән саен, игенче киләчәк турында күбрәк уйлый. Август сынамышларының күбесендә кыр эшләрен үз вакытында үткәрү, кышка әзерләнү турында күп төрле киңәшләр бирелә.

Август — урак ае. Арыш, арпа өлгереп җитә, бодайларның башаклары тула, солы җитешә. Игенче шуларның барысын да җыеп алырга ашыга. Җәйнең матурлыгы белән хозурланырга авыл кешесенең вакыты юк: күп көч куеп үстергән игеннәрне түкми-чәчми җыеп алырга кирәк. Халык мәкальләре шул хакта искәртә: «Игенне иң элек бурага салдым диген, аннары уңыш алдым диген». Мәктәптә механизатор һөнәренә өйрәнгән егетләр комбайнда әтиләре белән бергә эшли. Яшелчә, җимеш бакчаларында мәктәп балалары кыяр, помидор, алма җыярга булышалар. Август — җиләк-җимеш өлгергән ай. Август — гөмбәләр ае.

Талгын җил исә. Ашлык исе килә. Басу юлларыннан авыр йөк төягән машиналар чаба. Алар элеваторларга ашлык ташыйлар. Урып-җыю эшләре белән беррәттән, көзге чәчүгә әзерләнәләр. Игеннәрдән бушаган басуларны сөрәләр. Һәр нәрсәнең үз вакыты бар. Бер көн алдан чәчсәң, бер атна алдан урырсың, диләр игенчеләр. Басуларның төсләре дә төрле: берсендә ямь-яшел булып кукуруз үсеп утыра, икенчесендә сап-сары бодай чайкала, өченчесендә яңа сөрелгән кара буразналар сузылган.

Бакчалар шау чәчәктә. Гөлләр гөлләрне алыштыра: флокс, георгин, астраларның ниндиләре генә юк!

Урманда балкып утырган чәчәкләр кими бара. Гөләпнең кып-кызыл җимешләре өлгерә, ерактан миләш тәлгәшләре кызарып күренә. Чикләвекләр дә тәмам өлгергән чак.

Көннәр шактый кыскара, сүрелә, төннәр озая. Иртәләрен елга-күлләр өстендә ак томан тирбәлә. Күктә сыерчыклар, кара каргалар төркем-төркем булып оча. Тирә-якта — кошлар тавышы. Алар туган яклары белән саубуллашалар. Ямансу булып китә.

Каен, юкә агачларындагы алтынсу сары яфраклар көз якынлашуын хәбәр итәләр.

